**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**

**Азнакаевского**

**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево,
423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс
(885592) 7-23-85
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай
шәһәре, 423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс (885592)
7-23-85
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**"__26__" ___04___ 2023 ел** **№_121_**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының
Әлкәй авыл җирлегенең генераль планы (Үзгәрешләр
кертү) проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән җитәкчелек итеп, карар итәм:

1. Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлегенең Генераль планы (Үзгәрешләр кертү) проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлаулар уздыруның инициаторы - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башлыгы.

3. Билгеләргә:

- Үткәрү вакыты: 2023 елның 27 апреленнән 2023 елның 22 маена кадәр 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрелү урыны: Азнакай районы, Әлкәй авылы, Совет тыкрыгы, 44а йорты;

- 2023 елның 22 маена кадәр тикшерелә торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелергә мөмкин булган адрес: Азнакай шәһәре, М.Солтангалиев ур., 24 йорт, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктур үсеш бүлеге; Азнакай районы, Әлкәй авыл җирлеге, Әлкәй авылы, Совет тыкрыгы, 44А йорт, Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге башкарма комитеты.

4. Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең генераль планы (Үзгәрешләр кертү) проекты буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән вакытта гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

- Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең генераль планы (Үзгәрешләр кертү) проекты материалларын Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлегенең генераль планы

(Үзгәрешләр кертү) проекты турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен әзерләү буенча эш төркеме составын кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырырга һәм Азнакай муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatarstan.ru, шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык М.З. Шәйдуллин

Азнакай муниципаль районы башлыгы карарына кушымта
"_____"________ 2023 №______

Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең генераль планы (Үзгәрешләр кертү) проектын тикшерү буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында нәтиҗә әзерләү буенча
эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| *Эш төркеме рәисе:* | |
| А.Х. Шәмсетдинов | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| *Эш төркеме секретаре:* | |
| Әюпова Р.Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктур үсеш бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| *Эш төркеме әгъзалары:* | |
| Шәрәфетдинова С.Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктур үсеш бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Зиннурова С.З. | Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сабирҗанов Н.Г. | Азнакай район Советы җирлекләре белән эшләү секторы мөдире |